**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Төги авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

**№ 88** **31.01.2023 ел**

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Төги авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында» 2014 елның 21 февралендә 104 номерлы Зәй муниципаль районы Төги авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 05 декабрендәге 498-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2022 елның 28 декабрендәге 569-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Зәй муниципаль районы Төги авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Төги авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Төги авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында» 2014 елның 21 февралендә104 номерлы Зәй муниципаль районы Төги авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. 15 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 11 пунктны өстәргә:
«11) алар тарафыннан чит ил агенты статусы алу.»;
1.2. 24 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 5 пунктны өстәргә:
«5) муниципаль хезмәткәр тарафыннан чит ил агенты статусын алу.»;
1.3. 35 статьяның 4 пунктында «Россия Федерациясе Пенсия фонды» сүзләрен «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды» сүзләренә алмаштырырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), җирлекнең торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль

районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.
3. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Совет рәисе** **Т.В. Попова**